**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ВЕРХНЕКАМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
улица Дружба, дом 7, село Ибраево Каргали, 423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛ СОВЕТЫ**
Дружба урамы, 7 йорт, Ибрай Каргалы авылы, 423108

тел./факс (84396) 2-31-60/2-34-16 email: Vkam.Cmn2@tatar.ru

№ 114 20 июнь 2024 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Юргары Кәминкә авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге депутатларының, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайлап куелган җирле үзидарә вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 80 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларына, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларына, депутатларга, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлап куелган җирле үзидарә органнары әгъзаларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларына айлык акчалата бүләкләү күләмен арттыру турында» 2024 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге депутатларының, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайлап куелган җирле үзидарә вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 80 номерлы карарына (җирлек Советының 2018 елның 15 ноябрендәге № 96; 2020 елның 19 октябрендәге № 7; 2022 елның 21 ноябрендәге № 71 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге

үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 өлешнең 3 абзацын бәян итәргә: «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең хезмәт хакы күләме 13323 сум тәшкил итә»;

1.2. «Айлык акчалата бүләкләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм түләү күләме» 7 нче кушымтасында 1 нче пунктны бәян итәргә:

«1. Югары Кәминкә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә премиядән тыш ай саен акчалата бүләкләүләр дә түләнә. Муниципаль хезмәткәрләргә айлык акчалата бүләкләү җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән вазыйфаи хезмәт хакының 41 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә.

1.3. 3 нче кушымта «Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен» кушымтага ярашлы рәвештә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Югары Кәминкә авыл җирлеге**
**Советы рәисе, башлыгы** **М.Н.Минһаҗев**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге
Советының 2024 елның 20 июнендәге
№ 114 карарына кушымта

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге
Советының 2018 елның 25 апрелендәге
№ 80 карарына 3 нче кушымта

Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 18260 |